| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2025 Девәтернә авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 1нче этабын 2025 елның 23 октябрендә 10сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 2нче этабын 2025 елның 23 октябрендә 11сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Югары урам, Дәбер урамы, Ленин урамында яшәүчеләр.

-2 этап: Лесхоз урамы, Яңа урам, Су юлы урамы, Чишмә урамы, Совет урамы, Мәктәп урамында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәттәгеләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекелләр) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балалары) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (авария хәлендәге һәм корыган агач-куакларны кисү һәм чыгару, чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ленин урамындагы чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, дроссель, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; урам утларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар);

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү

“КИЛЕШӘМ” “КАРШЫ”.

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Девәтернә авылы, Совет урамы, 48нче йорт, авыл мәдәният йорты адресы буенча уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге Башлыгы Э.Э.Ганиев